ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 17 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2012, № 3; 2014 № 6 (II өлеш) түбәндәге эчтәлекле бишенче һәм алтынчы өлешләр өстәргә:

«Гражданхәле актын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык рус телендә тутырыла, анда гражданхәле актын дәүләт теркәвенә алу турында татар телендә белешмәләр була.

Гражданхәле актын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкны тутырганда кулланыла торган гражданхәле актын дәүләт теркәвенә алу турындагы татар телендәге белешмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданхәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләрне алар тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр әлеге Законга 1 нче кушымтада каралган Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләү методикасы нигезендә бирелә.»;

2) 2 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4 статьяның 2 өлешендәге өченче абзацында «граждан хәле актлары язмаларының беренче һәм икенче нөсхәләрен» сүзләрен «граждан хәле актлары язмаларының кәгазь вариантларын» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «, граждан хәле актларын язу бланклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «, граждан хәле актларын язу бланклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 7 статьяда:

а) исемендә «Граждан хәле актлары язмаларының беренче нөсхәләрен» сүзләрен «Граждан хәле актлары язмаларының кәгазь вариантларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «төзелгән граждан хәле актлары язмаларының беренче нөсхәләре» сүзләрен «тутырылган граждан хәле актлары язмаларының кәгазь вариантлары» сүзләренә алмаштырырга;

6) $7^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2016 елның 7 маендагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 5) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

1. Әлеге Закон, аның 2 статьясындагы 1, 2 пунктларыннан тыш, 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 1, 2 пунктлары бу Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2017 ел, 27 апрель
№ 27-ТРЗ